КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 595

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 21 нче; 2007 ел, 20 август, 399 нчы; 2007 ел, 6 декабрь, 690 нчы; 2009 ел, 25 май, 335 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 871 нче; 2010 ел, 31 август, 688 нче; 2012 ел, 19 июнь, 523 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 19 нчы; 2015 ел, 4 март, 133 нче; 2016 ел, 17 май, 320 нче; 2018 ел, 12 апрель, 237 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.М.Сибагатуллинны, М.Р.Гаффаровны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Хафизҗан кызы Әюпованы;

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары Рөстәм Фәйзрахман улы Вәлиуллинны;

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре буенча министры Дамир Илдус улы Фәттаховны;

Сергей Альбертович Осипов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары»;

Владимир Александрович Леонов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының спорт министры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин